**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Поповка авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**22.09.2020 ел** **№ 6**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Поповка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен тапшыру турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирлекнең бюджет процессын оештыру буенча аерым вәкаләтләрен тапшырырга.
2. Җирлекнең бюджет процессын оештыру буенча муниципаль район тарафыннан аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында килешүне (кушымта) расларга.
3. Әлеге карарны үтәү йөзеннән, "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Поповка авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенә җирлекнең бюджет процессын оештыру буенча аерым вәкаләтләрен муниципаль район тарафыннан башкару турында килешү төзергә.
4. Карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.
5. Карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе** **И.А.Амерханов**